РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

КАРАР ПОСТАНОВЛЕНИЕ

19.02.2026 №196-п

Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 9 октябрендәге 817-п номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә барлык төр милек формасындагы спорт инфраструктурасы объектларын инвентаризацияләү тәртибен раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Саба районы прокуратурасының протестына бәйле рәвештә, Россия Спорт Министрлыгының «Спорт объектлары классификаторын раслау турында» 2024 елның 03 июлендәге 639 номерлы боерыгын кабул итү уңаеннан, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

**1.** Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 9 октябрендәге 817-п номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә барлык төр милек формасындагы спорт инфраструктурасы объектларын инвентаризацияләү тәртибен раслау турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. 4 нче кушымтаның II бүлегенең 1 пунктындагы икенче абзацында «Россия Федерациясе Спорт Министрлыгының 2016 елның 25 февралендәге 172 номерлы боерыгын» сүзләрен «Россия Федерациясе Спорт Министрлыгының 2024 елның 03 июлендәге 639 номерлы боерыгын» сүзләренә алыштырырга;

1.2. 4 нче кушымтаның 2 нче пунктында «Россия Федерациясе Спорт Министрлыгының 2016 елның 25 февралендәге 172 номерлы боерыгын» сүзләрен «Россия Федерациясе Спорт Министрлыгының 2024 елның 03 июлендәге 639 номерлы боерыгын» сүзләренә алыштырырга;

1.3. Комиссия составын яңа редакциядә расларга.

**2.** Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми рәвештә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча халыкка җиткерергә.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты
Җитәкчесе М.Р. Кәримов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
«___»________2026 ел №____
карары белән РАСЛАНГАН

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы территориясендә
барлык төр милек рәвешләрендәге спорт инфраструктурасы объектларына
инвентаризация үткәрү комиссиясе составы

Комиссия рәисе:
М.Р. Кәримов – Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе.

Комиссия рәисе урынбасары:
А.Х. Гатиятуллин – Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгы.

Комиссия секретаре:
Э.Д. Рамазанов – Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы.

Комиссия әгъзалары:
И.Ф. Шакиров – Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе МКУ башлыгы;

Р.Ф. Заһидуллин – Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының мәдәният бүлеге башлыгы;

А.М. Галиуллин – Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе;

Ш.А. Сөнгатов – Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе;

Р.Р. Сөнгатуллин – Татарстан Республикасы «Техник инвентаризация һәм кадастр эшләре бюросы» АЖ Саба бүлекчәсе җитәкчесе.